УДК 821.512.145

***Ә.Н. Нәҗипова***

# ТУКАЙНЫ ӨЙРӘНҮ ФӘНЕНДӘ ӘДӘБИЯТ ГАЛИМЕ ҺӘМ ТӘНКЫЙТЬЧЕ Ф. ГАЛИМУЛЛИН ЭШЧӘНЛЕГЕ
***(галимнең 80 еллык юбилее уңаеннан)***

В статье рассматривается анализ биографии и творчество Габдуллы Тукая в учебниках, в учебниках-хрестоматиях по татарской литературе, автором которых является профессор Фоат Галимуллин, составленные для татарских и русских классов. Рассказывается о роли известного ученого, педагога, методиста Ф. Галимуллина по пропаганде среди молодежи деятельности Габдуллы Тукая, тем самым стремление автора воспитывать у школьников и студентов любовь к поэту, к татарскому языку и татарскому народу. В статье также рассматривается и научные статьи ученого, анализируется его взгляды к личности и творчеству поэта.

Ключевые слова: Габдулла Тукай, татарский народ, любовь к языку, мысли, методика, педагогическая и методическая деятельность, воспитание.

The article deals with the analysis of Gabdulla Tukai's biography and work in textbooks, in textbooks-anthologies on Tatar literature, authored by Professor Foat Galimullin, compiled for Tatar and Russian classes. The article describes the role of the famous scientist, teacher, methodist F. Galimullin in promoting the activities of Gabdulla Tukai among young people, thus the author's desire to educate schoolchildren and students to love the poet, the Tatar language and the Tatar people. The article also examines the scientific research of the scientist, analyzes his views on the personality and creativity of the poet.

Keywords: Gabdulla Tukai, Tatar people, love of language, thoughts, methods, pedagogical and methodological activities, education.

Еллар үтә, чорлар алышына, ләкин татар халкының йөрәк моңы булган Тукай иҗатына карашлар яңара, тирәнәя генә бара. Татар әдәбиятын, аның тарихын, үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнгән һәм киң җәмәгатьчелеккә чыгарган, шагыйрьдән соң бер гасыр соңрак яшәп иҗат итүче галим Фоат Галимуллин эшчәнлегенең бер тармагын бөек шагыйрь Габдулла Тукай иҗатын озак еллар буена эзлекле өйрәнү тәшкил итә. Һәм бу тикшеренүләрнең нигезен Тукай шәхесен, иҗатын төрле яссылыкта, төрле дәрәҗәдә һәм юнәлештә җентекле анализлау тәшкил итә. Ф. Галимуллин – Габдулла Тукай биографиясен, иҗатын төрле юллар белән яшь буынга җиткерү, Тукайның татар халкыннан аерылгысыз булуын исбатлау аша киләчәк буыннарда аңа карата ихтирам тәрбияләү һәм татар әдәбияты үсешенә зур өлеш керткән шагыйрьне онытмауның милләтнең киләчәге өчен никадәр әһәмиятле булуын исбатлаган галим, методист, педагог, җәмәгать эшлеклесе. Шуңа күрә без, Ф. Галимуллин – Габдулла Тукай иҗатын киң планда өйрәнгән, әлегәчә булган тикшеренүләрне тагын да

тирәнәйтеп анализлаган галим, дип әйтә алабыз. Ул татар шагыйренең иҗатын яшь буынга – мәктәп укучыларына, югары уку йортлары студентларына төрле елларда төзелгән күпсанлы дәреслекләре, методик кулланмалары, сәнгатьле уку буенча язган китаплары аша ирештерә. Аның тарихи фактларга таянып язылган хезмәтләрендә бу җитди мәсьәлә тагын да киңрәк һәм берничә юнәлештә өйрәнелә: шуларның берсе – Тукай иҗатын әдәби-эстетек анализлау, икенчесе – аны чор каршылыкларына бәйләп карау, өченчесе – төрле чорларда әйтелгән фикерләрне анализлау, тикшерү ярдәмендә шагыйрь шәхесенә, аның тулаем эшчәнлегенә аек, дөрес караш булдыру һәм, ниһаять, Тукайның башка язучылар иҗатына йогынтысын, тулаем татар әдәбиятын үстерүдәге ролен билгеләү.

Ф. Галимуллин мәктәпләр өчен төзегән дәреслекләренә татар әдәбиятының йөзек кашлары булган Гафур Коләхметов, Галиәсгар Камал, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Мирхәйдәр Фәйзи, Һади Такташ, Шәриф Камал, Гадел Кутуй иҗатларын кертү белән бергә, Габдулла Тукай иҗатын киң планда өйрәнүгә зур игътибар бирә. Төрле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге мәктәпләрдә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре буенча зур эш башкарган галим, Габдулла Тукай иҗатын балаларга өйрәткәндә, үзе төзегән дәреслекләрдә гомуми педагогик принцип – хронологик тәртипне саклап, баланың яшь үзенчәлеген истә тотып, шагыйрьнең биографиясен, әсәрләрен һәр укучы күңеленә үтеп керерлек итеп анализлый, үзе кулланган материалларда, аның бөеклеген исбатлап, яшь кеше күңелендә бу шәхескә мәхәббәт уятуны максат итеп куя, шуның ярдәмендә туган телдә – татар телендә милли кануннарны алга сөреп, рухи мохит булдырырга омтыла. Ф. Галимуллин мәктәп дәреслекләренә әсәрләр сайлаганда игътибарлы, алдан күрүчән булырга кирәклекне искәртеп, Габдулла Тукай сүзләрен китерә: «Әдәби әсәрләрне букет итеп күз алдына китереп булыр иде. Бала кулына син кычыткан тоттырасыңмы, әллә инде матур чәчәкләрдән торган букет тоттырасыңмы? Ул шул букет аркылы тормышны танып белә башлый. Матур әсәрләр җыелмасы тормышның матур якларын күрергә өйрәтә» [Галимуллин, 1995, б. 239]. Һәм төзүче-автор, тулы бер гасыр үтеп, җәмгыять тормышы нинди генә үзгәрешләр кичерсә дә, Габдулла Тукай фикерләренең актуаль, әһәмиятле булуын раслый. Ф. Галимуллинның төрле елларда төзелгән дәреслек, методик кулланмаларында инде күп галимнәр, әдәбият белгечләре һәм башка бик күпләр тарафыннан исбатланган шушы хакыйкать ачык чагыла. Авторның төрле елларда төзелгән – 1987 елда 9 нчы сыйныф өчен туган тел һәм әдәбият дәреслеге (С. Ибраһимова белән берлектә), 1991 елда 10 нчы сыйныф өчен туган тел һәм әдәбият дәреслеге (К. Мифтахова, С. Ибраһимов белән берлектә), 1995 елда рус мәктәпләренең 6 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия (Ф. Мифтиева, И. Гыйләҗев белән бергә), 1995 елда татар урта гомуми белем мәктәбенең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек (А. Әхмәдуллин, Т. Галиуллин, Ф. Ганиева,

Н. Юзиев белән бергә), 2000 елда 10 сыйныфлар өчен (М. Хәсәнов, А. Әхмәдуллин, И. Нуруллиннар белән бергә), 2001 елда шундый ук мәктәпләрнең 7 нче сыйныфы өчен дәреслекләрдә (Ф. Хатипов белән бергә) бер максат ачык ярылып ята, ул – шагыйрь иҗаты аша татар тарихына, халкына, татар әдәбиятына мәхәббәт уяту, һәм шулар аша халкыбызның зурлыгын, бөеклеген раслау, яшь буында үз милләтең белән горурлану хисе уяту.

Рус мәктәпләренең 6 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен 1995 елда төзелгән татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматиясендә дә, 2014 елда төзелгән рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар әдәбияты дәреслекләрендә дә (Ф.Г. Галимуллин редакциясендә, 4 – 11 нче сыйныфлар өчен) әнә шул үзенчәлекләр истә тотылган, күрәсең. Мәсәлән, татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең 10 нчы сыйныфы (Ф.Г. Галимуллин, М.Х. Хәсәнов, А.Г. Әхмәдуллин, 1994) дәреслегендә Тукайның биографиясен биргәндә, төрле тарихи, кызыклы материалларны куллану, иҗатын яктыртканда, шагыйрьнең үз шәхесен милләт язмышы (үткәне, бүгенгесе, киләчәге) белән үреп карау, шигырьләренең теленә, музыкальлегенә, халык иҗаты, башка әдәбиятлар белән бәйләнешенә киң тукталу, һәм боларның барысын нигезле өйрәнү һәм өйрәтү максатыннан, һәр бүлек ахырында төпле сораулар кую, сүзлек өстендә эш, материалны өйрәнүгә күп вакыт билгеләү теманы нигезле, тулы итеп ачарга мөмкинлек тудыра.

Билгеле булганча, сиксәненче елларга кадәр татар теле һәм әдәбияты рус мәктәпләренең түбән һәм урта сыйныфларында факультатив рәвешендә генә өйрәнелде. Бары тик сиксәненче еллар ахырында гына туган телне һәм әдәбиятны бу мәктәпләрнең өлкән сыйныфларында да өйрәнә башладылар. Ф. Галимуллин (укытучы-методист С.М.Ибраһимов белән берлектә) – тугызынчы сыйныфлар өчен беренчеләрдән булып дәреслек язган автор. Әлеге дәреслектә әдәбият чорларга бүлеп өйрәнелә. Дәреслекнең беренче битләрендә әдәбиятның борынгы чоры турында шактый гына мәгълүмат бирелгәннән соң, XX гасырда яшәп иҗат иткән әдипләр турындагы материаллар тупланган. Автор шулар арасыннан Тукай иҗатын өйрәтүгә аерым игътибар юнәлтә. Китапта, беренчедән, шагыйрьнең биографиясе киң яктыртылган, икенчедән, «Китмибез», «Теләнче» һ.б. шигырьләре мәктәп баласына аңлаешлы, аның күңеленә барып җитәрлек итеп анализланган.

Рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләре өчен 2014 елда төзелгән татар әдәбияты дәреслекләрендә дә (Фоат Галимуллин редакциясендә, 4 – 11 сыйныфлар өчен) Г. Тукай иҗаты төрле милләт балаларына, рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына рус һәм башка милләт балалары белән дустанә мөнәсәбәт урнаштыру зарурлыгын күз алдында тотып аңлатылган. Гомумән, Ф. Галимуллинның төрле сыйныфларда Габдулла Тукай иҗатын өйрәнүне методик һәм педагогик яктан куелган стандартларга туры китереп бирүе, биографиясен,

иҗатын киң планда яктыртуы, бер яктан, аның яшь буында милләтебезгә, телебезгә хөрмәт уятырга омтылуы булып аңлашылса, икенче яктан, галимнең үз шәхси мөнәсәбәтен дә ачыкларга мөмкинлек тудыра. Ф. Галимуллинның Габдулла Тукайга багышланган мәктәп китапханәсе сериясендә чыккан китабы зур әһәмияткә ия. Бу дәреслек-хрестоматия яшүсмерләргә сыйныфтан тыш эшләрне оештырганда (мәсәлән, сыйныфтан тыш уку өчен) кулланма булып тора ала. Автор беренче биттә үк «Шагыйрь турында истәлекләр» дип билгеләп китә һәм, китапны уку барышында, укытучыга да, укучыга да әлегә кадәр мәктәпләр өчен язылган дәреслек, әсбапларга кертелмәгән бик кызыклы материаллар белән танышырга мөмкинлек тудыра. Мәсәлән, шагыйрьнең биографиясе хронологик тәртиптә бирелгәннән соң, бер чорда яшәгән, иҗат иткән, татар халкын аңлы-белемле итү өчен тырышкан Г. Камал, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан кебек шәхесләрнең Тукай белән беренче тапкыр очрашулары, әлегә кадәр басылган шигырьләре буенча гына белгән шагыйрьне күргәннән соң, күңелләрендә туган беренче фикерләре китерелә. Өзекләрдә Тукай – гади, буйга да зур күренми, ләкин төскә-башка ямьсез түгел, дип сурәтләнә. Әнә шул кечкенә гәүдәгә – эчке байлык, беркатлы, балалар кебек самими күңелгә зур рухи көч сыйган. Ф. Галимуллин Г. Тукайның замандашлары истәлекләре аша талантлы, булдыклы, якты шагыйрь образын тудыра. Галим Г. Тукайның шигърияткә килүендә табигый талант һәм татар халкының мәдәнияте зур роль уйнавын ассызыклый. И. Гаспралы, К. Мотыйгый кебек шәхесләр белән очрашу, эшләү, аларның фатихасын алуның Тукай язмышында әһәмиятле роль уйнавын галим тарихи мисаллар китереп исбатлый. Көнчыгыш, Көнбатыш, рус, башка халыклар әдәбиятларын тирәнтен өйрәнү, белү, анализлап карау аша шагыйрьнең татар халкының киләчәген күрүе, әдәбият, мәгърифәт, гомумән, мәдәният өлкәсендә үсешкә ирешү юлларын күрсәтергә омтылуы – аның эшчәнлегендә, иҗатында ничек чагыла? Шагыйрьне нинди мәсьәләләр борчый? Без, болардан чыгып, бүген милләтебезнең яшәеше турында ничек фикер йөртергә тиешбез? Ф. Галимуллинның Тукай турында язганнарыннан әнә шундый әһәмиятле фикерләр аңлашыла. Китапның икенче өлешендә бөек шагыйрьнең әсәрләре тәкъдим ителә. Автор аларны башта гомуми исем белән сайланма әсәрләр дип атый, аннан шигырьләр, поэмалар, проза, мәкаләләр, хатлар дип, жанр ягыннан һәм тематика буенча бүлә. Бу исә, укытучыга да, укучыга да кирәкле мәгълүматны бик тиз табып алырга мөмкинлек тудыра. Ахырдан бик күп истәлек-хатлар китерелү дә китаптагы материалны кызыклы итә, баета. Гомумән, Ф. Галимуллин, үзенең дәреслекләре, методик әсбаплары, күпсанлы чыгышлары белән укучылар арасында татарның бөек шагыйре Габдулла Тукай иҗатын киң пропагандалаган галим, педагог, методист дисәк, һич тә ялгыш булмас. Аның дистә еллар буе радио-телевидениедән Габдулла Тукай шигырьләрен сәнгатьле итеп укып, татар укучысына ишеттерүен дә шагыйрьнең милләткә никадәр кирәкле булуын исбат-

лавы, яшь буынны Тукай шәхесе рухында тәрбияләргә омтылуы дип аңларга кирәктер.

Алда билгеләп үтелгәнчә, Фоат Галимуллинның гаять күпкырлы, киң колачлы эшчәнлегенең бер мөһим өлкәсен нәкъ менә әдәби тәнкыйть тәшкил итә. Галим әдәби тәнкыйть мәйданына узган гасырның җитмешенче елларында килеп керә һәм шуннан бирле тәнкыйть каләмен кулыннан төшерми. Аның тәнкыйте бер генә юнәлешле түгел, ә күп тармаклы: әдәби тәнкыйть, театр тәнкыйте, сәнгать тәнкыйте, музыка тәнкыйте.

Тәнкыйтьче буларак, ул җанлы әдәби хәрәкәткә һәрвакыт үзенең мөнәсәбәтен күрсәтеп яза. Ф. Галимуллин тәнкыйтьче шәхесе өчен зарур булган сыйфатларның барысына да ия: теоретик әзерлек, киң мәгълүматлылык, иҗат үзенчәлекләрен тирән сиземләү, таләпчәнлек һәм югары әхлаклылык, ихласлык. Галим, тәнкыйтьче буларак, әдәби процессның иң мөһим нокталарын, проблемаларын күреп ала белә, шуларны көн тәртибенә куя, сөйләшү, тикшерү объектына чыгара, үзенең төпле фикерен әйтә, әдәби фикерне кузгата. Ул, йөз елдан соң шагыйрь тормышына, иҗатына әйләнеп кайтып, әнә шушы без алда санап киткән принципларга таянып эш итә.

Аның 2005–2010 еллар аралыгында язылган хезмәтләре төрле язучыларның шәхесен, иҗатын анализлауга багышланган мәкаләләрдән тора, аларның күпчелеге «Эзләнү вакыты» (2005) исемле китапта басылып та чыкты. Мәкаләләр арасында Г. Тукай эшчәнлеген өйрәнеп язылганнары аерым урын били. Галим «Халыкның үз шагыйре» мәкаләсендә әдип яшәгән чор әдәби күренешләрен һәм иҗатын аның шәхесе, тормыш-яшәеш хәлләре, биографик фактлары белән тыгыз бәйләнештә бәяли. Бу мәкалә тагын бер ягы белән кызыклы һәм кыйммәтле: галим анда әлегә кадәр Тукай турында әйтелгән күп кенә фикерләрнең дөреслеккә туры килеп бетмәвен (мәсәлән, аның биографиясенә, портретына, үз чорының башка күренекле шәхесләре белән мөнәсәбәтләренә кагылышлы мисаллар) тарихи документлар, реаль фактларга таянып дәлилли. Әлбәттә, галим төп игътибарны шагыйрь иҗатына, аның татар шигъриятендә биләгән урынына юнәлтә. Татар шигърияте тарихында үзенә бер аерым урын алып торган, бик кыска гомерендә мең елга җитәрлек эш башкарып киткән, «...Урта гасырлар һәм XIX гасыр әдәбиятлары казанышларына таянып, татар сүз сәнгате үсешенең яңа дәверенә нигез салды; шигъриятебезне сәнгатьлелек ягыннан гаять югары дәрәҗәгә күтәреп, аның дөнья мәйданына чыгуын тәэмин иткән» [Галимуллин, 2005, б. 134] Г. Тукайның үз сүзләре белән әйткәндә, «Мин поэт кына түгел, мин дипломат, политик, общественный деятель дә бит. Минем күз күпне күрә, колак күпне ишетә» [Галимуллин, 2005, б. 145] торган олуг шәхес, бөек шагыйрьның күпкырлы эшчәнлеге ачыклана. Галим, Г. Тукай эшчәнлегенең зурлыгын, бөеклеген аның башка әдәбиятларга йогынтысы аша да аңлата. Үзбәкләрдән Хәмзә Хәкимзадә, Гафур Голәм, таҗик Садретдин Айни, азәрбайҗанлы Сөләйман Рөстәм, төрекмән Берды

Кербабаев, казакъ Җакан Сыздыков, чуваш Педер Хузангай һәм башкаларның истәлекләрен китереп, аларның танылуында Тукаебызның роле зур булуын исбатлый.

Күпгасырлык һәм бик бай, зур традицияле татар шигъриятенең төрле буын шагыйрьләре җилкәсендә бүгенге көнебезгә олы һәм затлы булып килеп җитүенең сәбәпчесе XX гасыр башы шагыйре Г. Тукай булу, аның яңа сулыш өреп, бу хәзинәне тагын да кыйммәтләндерүе, Һ.Такташ кебек икенче бер талантның аны тагын бер биеклеккә күтәрүе, соңрак, бу эстафетаны Х. Туфан, М. Җәлил, Ф. Кәримнәрнең дәвам итүе, С. Хәким, Г. Хуҗиев, С. Баттал, Ә. Исхакларның да шушы саваплы агымга кушылып, дәртләнеп иҗат итүе ассызыклана. Китап авторы киң планда, алдагы елларда язылганнарга янәдән әйләнеп кайтып, Габдулла Тукайның биографиясенә туктала. Монда тарихи һәм фәнни яктан әллә ни яңалык күренми кебек, ләкин мәкалә белән алга таба танышу барышында, шагыйрьнең «Исемдә калганнар»ыннан китерелгән биографик өзекләрнең бер дә артык булмавы, киресенчә, галим әйтәсе килгән фикерләрне тагын да баетып, тулыландырып торуы аңлашыла. Моннан тыш автор Тукайның бәргәләнеп-суккаланып йөрүенең сәбәпләрен, әти-әнисенең үлеме белән генә түгел, ә 1891 елда Идел буенда бик каты корылык нәтиҗәсендә туган ачлык белән бәйләп карый, димәк, бу елларда мохтаҗлыкка төшүчеләр, Тукай кебек ятимнәр, артык кешеләр шактый булган һәм аның социаль-иктисади сәбәпләре дә бар. Ләкин тормыш никадәр авыр булмасын, кешеләрнең, беренче чиратта, Габдулланың беренче мөгаллимәсе – Кырлай авылы остазбикәсе Маһруйбикә абыстай, Кырлайдагы хатиб һәм мөгаллим Фәтхерахман, Гатаулла хәзрәт кебекләрнең ничек булышулары тасвирланып, авырлыклар килгәндә, татар кешесенең бер-берсенә ярдәмчел, ә инде үзләре гыйлемлелекнең түмен татыган дин әһелләре, мөгалимнәрнең белем алырга омтылган яшь кешенең үсешенә һәрвакыт этәргеч бирергә әзер торуларын тагын бер кат исбатлый. Мәкаләдә киң планда Җаектагы Мотыйгулла хәзрәт Төхфәтулланың ятим малайны үз канаты астына алып, олы тормыш юлына чыгарга ярдәм итүе яктыртыла. Ундүрт яшьлек малай, җизнәсе үлгәч, апасы Газизә йортыннан «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә күчә. Шунда яши дә, укый да.

«Тормышның бу вакытында аңа Мотыйгулла хәзрәт матди һәм рухи ярдәм итүче булып әверелә. Үзенең яшьлек дустының малаен ул бик якын итә, йортына ияләштерергә, ашау-эчү якларын, кием-салымын кайгыртырга тырыша» [Галимуллин, 2005, б. 127]. «Габдуллага шигырь иҗат итү серләрен беренче булып өйрәтүче дә – Мотыйгулла хәзрәт. Бу төрле яклап галим кеше борынгы Көнчыгыш фәлсәфәсе һәм шигърияте, астрономиясе буенча да тирән мәгълүматлы кеше була» [Галимуллин, 2005, б. 127]. Ф. Галимуллин Мотыйгулла хәзрәтнең Тукайга кылган яхшылыкларын язып, бердән, бу шәхеснең күркәм образын тудыра, икенчедән, ятимлеккә дучар ителгән малай, нинди генә авырлыклар күрсә дә, тирә-ягында изге кешеләр булганда,

һәрдаим аларның ярдәмен тоеп торганда, аның үзенең дә шулар тәэсирендә зыялы шәхес булып тәрбияләнүен ачыклый. Әлбәттә, зыялылык мәсьәләсенә килгәндә, талант, тапкырлык, тырышлык, эшчәнлек, белемлелек һәм башка күп кенә сыйфатларны, беренче чиратта, нәсел җепләренә бәйләп карасак та, китапта бу гаиләнең (Мотыйгулла хәзрәт һәм аның улы Камил) Габдулланың шагыйрь булып китүендә дә, язганнарын бастыру мөмкинлеген тудыруда да ярдәмнәре зур булуы аерым мисаллар белән аңлатыла.

Ф. Галимуллин мәкаләдә Казанга кайткан Габдулланың замандашлары белән ничек очрашуы, алар күңелендә беренче очрашудан калган тәэсирләрне укучыга ирештерү максатыннан, түбәндәге өзекләрне китерә. Г. Камал: «Көннәрдән берендә кечкенә генә гәүдәле, өстенә абыйсының бишмәтен кигән шикелле» кием кигән, өтек кенә бер малай редакциягә керде дә, өстәл өстендәге газеталарны актара башлады. Я булмаса, Сәгыйть Рәмиев: «Номер ишегемне ачып:

– Сәгыйть әфәнде Рәмиев шушында торамы? – дип, бер малай килеп керде.

Карадым: яланбаш, кара күзлектән, өстенә казакимы, җөбәме, иске генә бернәрсә кигән бер малай, минем «ие» дигән сүземне дә көтмичә, каршымда, өстәл кырыенда, буш торган урындыкка килеп тә утырды... [Галимуллин, 2005, б. 129].

Күз алдына шагыйрьнең ике төрле портреты килеп баса: берсе – без хәзерге заман рәссамчылары тудырган матур, түгәрәк битле Тукай; икенчесе – галим тарихи язмалардан эзләп табып биргән кыяфәте белән әлләни булмаса да, «өстәл өстендәге газеталарны актара башлады», «минем «ие» дигән сүземне дә көтмичә, каршымда, өстәл кырыенда, буш торган урындыкка килеп тә утырды...» дигән өзекләрдән аңлашылганча, һәр җирдә, аеруча, әдәбият, сәнгать мәйданында һәрчак үзен хуҗа итеп тойган Тукай. Аларның кайсысы укучы күңеленә якын? Әлбәттә, икесе дә. Ләкин безнең халыкка тарихи хакыйкать кадерле, безнең халык үзе, үткәне, аның шәхесләре турында әйтелгән ясалма әйберләрне, ялганны ишетеп туйган. Шуңа күрә дә Ф. Галимуллинның Тукай турында һәр язганы, аның үз сүзләре белән әйткәндә, «безгә аның шәхесен аңлауда ачкыч булып хезмәт итү» белән бергә, шул чорда яшәгән һәм шагыйрь белән турыдан-туры бәйләнеше булган башка шәхесләрне аңлауда, тарихи дөреслекне укучыга ирештерүдә дә әһәмиятле роль уйный. Мәсәлән, галим «Туры сүз таш яра» мәкаләсендә Ә. Фәйзинең татар әдәбиятын үстерү буенча эшчәнлеге зур булуын күрсәтсә дә, әдипнең Г. Тукайга багышлап язган «Тукай Җаекта», «Тукай» һәм «Пугачев Казанда» драмаларын, «Тукай» романын язганда тормыш чынбарлыгыннан шактый читкә китүен билгели, ә инде Тукай шәхесен бәяләү, аның тормыш юлын алга таба өйрәнү, гомумән, хакыйкый әдәбият тарихын тудырганда, зур шәхесләр турындагы мондый хаксызлыклар әдәбият үсешенә комачаулык итүен исбатлый.

Шулай итеп, ул «Г. Тукайның шагыйрьлек сукмакларын тасвирлау, аеруча аның беренче адымнарын күрсәтү тарихи дөреслектән ерак тора», дип билгеләп, галим әдәбият тарихына яңа фикер өсти, шуның белән Тукай шәхесенә карата кайбер хаксызлыкларга чикләү куя. «Бигрәк тә аның шагыйрь булып формалашуына мөһим роль уйнаган, иҗатына зур этәргеч биргән Төхфәтуллиннар гаиләсе, аерым алганда Мотыйгулла һәм аның улы Камилнең йогынтысы, булышлыгы һәм хезмәттәшлеге бөтенләй яктыртылмаган. Бу да тарихи шәхесләрне сурәтләүгә шул ук «бүгенге совет тарихы фәне күзлегеннән чыгып карау нәтиҗәсе иде» [Галимуллин, 2005, б. 212], – дип билгеләп китүе, киләчәктә шагыйрь һәм ул яшәгән чор буенча кайбер мәсьәләләрне ачыклауның үтә зарур булуын аңлата.

Габдулла Тукайның шул чорның икенче бер зур шәхесе Галимҗан Ибраһимов белән булган каршылыклы мөнәсәбәтләрнең сәбәбен аңлатып, С. Хәкимнең бик тә урынлы әйтелгән сүзләрен китерә: «Галимҗан ашыккан, артык ашыккан... Икесе дә зур шәхес, Араларына кермим, Тукай да, Галимҗан да усал. Тукай җавапсыз кала торган кеше түгел. Шәхси яратып бетермәүләр язганнарыннан күренеп тора... Галимҗанның Тукай турындагы мәкаләләрен халык кабул итмәде. Халык Тукайга бөтенләй икенче төрле бәя бирде... Халыкка күбрәк ышанырга кирәк икән. Халык үз улын кимсетергә ирек бирми. Дөреслек – халык ягында» [Галимуллин, 2005, б. 159]. Ләкин Г. Ибраһимов Г. Тукайның шагыйрьлеген ничек кенә тәнкыйть итмәсен, «Ул халыкның эченә, җанына да төшә, хыял вә әкият дөньясына да керә» [Галимуллин, 2005, б. 159], дигән сүзләрне язып, ахыр чиктә аның «бәхәссез таланты»н танырга мәҗбүр булды, ди галим.

Тәнкыйтьче Нәкый Исәнбәтнең тууына 100 ел тулуга багышланган әлеге китабында («Зур талант, фидакяр галим»), аны шагыйрь, драматург, фольклорчы, тел белгече, тәрҗемәче, тарихчы, публицист буларак бәяләгәннән соң, Г. Тукайның Н. Исәнбәт иҗатына йогынтысы зур булуын ассызыклый. Н. Исәнбәтнең Сибгать ага Хәким тарафыннан китерелгән «зур шагыйрьләрдән Тукаев булса хәлфә, мин шәкерт» [Галимуллин, 2005, б. 220] сүзләрен мисалга китереп, шагыйрьнең яшь, әле генә каләм тибрәтә башлаган Исәнбәткә тәэсире зур булуын исбатлый. «Милләтем», «Моңланам мин...», «Мәрхүм Г. Тукаевка», «Тукай остаз» кебек шигырьләрендә яшь авторның Тукайга кабат-кабат әйләнеп кайтуын, аның зур фикер иясе булып китүендә шагыйрьнең ролен билгели. «Моны тою өчен шигырьләренең агышына колак салырга куша. «Г. Тукай вафаты уңае белән иң әүвәл шигырь язучыларның да берсе Нәкый Сираҗетдин углы була. Бу мәүзугка ул кабат-кабат әйләнеп кайта, «Милләтем», «Моңланам мин...», «Мәрхүм Г. Тукаевка», «Тукай остаз» кебек шигырьләрендә әле яшүсмер генә булган Нәкый зурларча фикер йөртә, үз алдына нәкъ Г. Тукайча олы бурычлар куя» [Галимуллин, 2005, б. 221].

Автор Габдулла Тукайның моңы, милли сулышы гасырлар буйлап бүгенге көн татар шагыйрьләре иҗатына килеп җитүен ассызыклап,

бу үлемсез хәзинәнең тугандаш төрки һәм Идел-Урал буйларындагы мари, удмурт, чуваш сүз сәнгатьләренең чәчәк атуына зур йогынты ясавын мисаллар өстендә дәлилләп китә, иҗаты шәхесеннән, шәхесе иҗатыннан, ә боларның икесе халыктан аерылгысыз булуын исбатлый.

Ф. Галимуллин Тукайның иң беренче шигырьләрендә үк халкыбызны мәгариф, фән өлкәләрендә уңыш яулап алырга чакыруына, үз милләтенә зур өметләр баглавына игътибар итә. Бу елларда язылган хезмәтләрендә галим үзе дә, әйтерсең, бөтен рухы белән шагыйрь әйткәннәргә кушыла һәм «Татарларның даны сигез кат күкләргә күтәрелүен тели» [Галимуллин, 2005, б. 135].

Габдулла Тукайның күпчелек шигырьләренең үзеннән-үзе җырлап торуына, ягъни музыкальлегенә игътибар итми мөмкин түгел [Галимуллин, 2005, б. 140], ди автор.

Үлемсез Тукайның халык авыз иҗаты белән кызыксынуын, аны тирәнтен өйрәнүен, шуңа күрә шигырьләренең дә халык теленә якын булуын төрле мисаллар өстендә исбатлаган галим, халык рухы шагыйрь әсәрләренең тукымасында бик табигый урын алуын ассызыклап, «Әллүки», «Тәфтиләү», «Зиләйлүк», «Туган тел» кебек җырларны «шулкадәр халыклашты ки, аларны шагыйрь иҗат иткәне сизелмәве – моның ачык дәлиле» [Галимуллин, 2005, б. 141], дип билгеләп үтә.

Ф. Галимуллин Габдулла Тукайның тәнкыйть мәкаләләренә игътибар итеп, аларда Габделҗәббар Кандалый, Утыз Имәни, Мифтахетдин Акмулла, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думавилар иҗаты шактый киң анализлануын ассызыклый. Хезмәттә авторның шулай ук Тукайның замандашлары Г. Камал, М. Гафури, С. Рәмиев, С. Сүнчәләй, Н. Думави, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый иҗатларына карата әйтелгән шактый әһәмиятле фикерләре дә урын алган.

Мәкаләләрдә Г. Тукайның иҗатына карата Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Г. Ибраһимовларның уңай һәм тискәре бәяләре, галимнең әйтелгәннәргә карата үз фикере чагылыш тапкан, Габдрахман Сәгъди, Гали Рәхим, Фәтхи Бурнаш, Галимҗан Нигъмәти, Җамал Вәлиди, Гомәр Гали кебек күренеклеләрнең эшчәнлекләренә киң планда тукталып, фәнни нәтиҗәләр ясалган.

Галим төп игътибарын И. Нуруллинның 1956 елда басылган «Тукай эстетикасы» дигән хезмәтенә юнәлтә. «Атаклы кешеләр тормышы» сериясеннен «Тукай» дигән әсәрнең язылу тарихы шактый киң яктыртылып, аның төрле чорлар өчен зур әһәмияткә ия булуы, шагыйрьне, шагыйрь аша татар милләтенең үлемсезлеген билгели. Шулай ук Ә. Фәйзинең «Тукай» романы һәм «Тукай Петербургта» драмасы бөек шагыйребезнең шәхесен укучыларга һәм тамашачыларга танытуда файдалы эш икәнлеге, Р. Ишморат, Т. Миңнуллин, Р. Батулланың драма әсәрләрендә, С. Хәким поэмаларында, күпсанлы шигырьләрдә, хикәяләрдә Тукай образының төрле яклап һәм шактый тулы гәүдәләндерелүе, моның ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүе

һәм Тукай шәхесенә игътибарның киң планлы булуының татар халкы өчен ни дәрәҗәдә кыйммәтле һәм әһәмиятлелеге Ф. Галимуллинның югарыда аталган фәнни хезмәтләрендә чагылыш тапкан.

Тулы бер гасыр дәвамында Г. Тукайга багышлап язылган бик күп җырлар, музыкаль, рәсем һәм сынлы сәнгать әсәрләре үзләре үк Тукай иҗатының кыйммәте, әһәмияте турында сөйли, «Бөек шагыйребез әнә шулай халкыбыз рухында яши. XXI гасырга да ул олуг шагыйрь, зур җәмәгать эшлеклесе, бөек фикер иясе буларак килеп керде» [Галимуллин, 2005, б. 161], дип фикерен йомгаклый галим.

«Олы гомер йомгагы. Туры сүз таш яра» мәкаләсендә М. Гафури иҗатын күздән кичереп, галим аны Г. Тукай белән чагыштыра. Каләм әһеленең әүвәл язган әсәренең «Фәкыйрьлек берлә үткән тереклек» дип аталуы да юкка түгелдер, дип билгели Ф. Галимуллин. «М. Гафури, үзенең чордашлары Г. Исхакый, Г. Тукайлар кебек үк, нәкъ менә тормышны реалистик итеп, ягъни чынбарлыктагыча сурәтләү юлыннан китә» [Галимуллин, 2005, б. 203].

Галимнең Габдулла Тукай иҗатын өйрәнү, өйрәнгәннәрен башкаларга тарату буенча эшчәнлеге – күп елларга сузылган, җентекле тикшеренүләр таләп иткән зур хезмәт. Фоат Галимуллинның үз сүзләре белән әйткәндә, «Язучының җәмгыятьтәге урыны туган халкының кояшыбыз астындагы урыныннан, аның тулаем язмышыннан бәйле. Шул язмышның якты булуына каләм осталары кертә торган өлеш кимемәскә тиеш! Мин моңа ышанам, һәрхәлдә, шуңа өметләнәм!» [Галимуллин, 2005, б. 52]. Бу сүзләр Ф. Галимуллинга кадәр бер гасыр алда яшәп иҗат иткән, язмышын милләте язмышы белән бәйләгән, милләт шатланганда шатланган, милләт кимсенгәндә үзен хәсрәтле хис иткән татар шагыйре Габдулла Тукай турында да, үзе өчен, милләте өчен бик тә әһәмиятле булган – тел, ирек, дәүләтчелек кебек мәсьәләләрне чишәргә тырышып та, чишеп бетерә алмаган башка фикер ияләре, иҗат кешеләре хакында да һәм, ниһаять, гомерен татар милләтенә хезмәт итүгә багышлаган, һәрдаим аның киләчәге өчен борчылып яшәгән галимнең үзе турында да дип аңларга кирәктер. Гомумән алганда, Фоат ага Галимуллинның озак еллар буе әдәбият фәне өлкәсендәге эшчәнлегенең зур бер тармагын олуг шагыйрь Габдулла Тукайның биографиясен, иҗатын тарихи дөреслеккә таянып өйрәнү, өйрәнгәннәрен, әлегә кадәр башка бик күп татар зыялылары язып калдырганнарны яңа фикерләр белән баетып үстергән хәлдә, хәзерге һәм киләчәк буыннарның аңына барып җитәрлек итеп таныту тәшкил итә.

**Әдәбият**

Әдәбият дәреслеге: 9 нчы сыйныф өчен / Ф.Г. Галимуллин, С.М. Ибраһимова. Казан: 1987. 213 б.

Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбе. 11нче сыйныф өчен дәреслек / Ф.Г. Галимуллин, А.Г. Әхмәдуллин, Т.Н. Галиуллин, Ф.Ә. Ганиева, Н.Г. Юзиев. Казан: 1995. 335 б.

Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбе. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек / Ф.Г. Галимуллин, М.Х. Хәсәнов, А.Г. Әхмәдуллин. Казан: 2000. 335 б.

Әдәбият: Татар урта гомуми белем бирү мәктәбе. 7 нче сыйныф өчен дәреслек-хрестоматия / Ф.Г. Галимуллин, Ф.М. Хатипов. Казан: Мәгариф, 2001. 183 б.

*Галимуллин Ф.* Әдәбият укытуның мөһим бурычлары // Мәгариф. 1995. № 9. Б. 12–14.

*Галимуллин Ф.* Эзләнү вакыты. Казан: Мәгариф, 2005. 246 б.

Татар әдәбияты: Рус мәктәпләренең 6 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия / Ф.К. Мифтиева, И.Г. Гыйләҗев, Ф.Г. Галимуллин редакциясендә. Казан: Мәгариф, 1995. 183 б.

Туган тел һәм әдәбият. Рус мәктәпләренең X сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия / Ф.Г. Галимуллин, С.М. Ибраһимова, К.Т. Мифтахова. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. 367 б.

*Тукай Габдулла.* Сайланма әсәрләр. Шагыйрь турында истәлекләр. Казан: Хәтер, 2002. 511 б.

***Нәҗипова Әлфинур Нурмөхәммәт кызы,***
*филология фәннәре кандидаты (Казан)*